БАЛТАСИНСКИЙ РАЙОННЫЙ
ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
БАЛТАЧ РАЙОН
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

«___21__» ____01_____ 2020 ел № _____34____

**«Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы авыл җирлекләренең генераль планнары проектын әзерләү буенча Нигезләмәне раслау һәм комиссия төзү турында» Балтач район башкарма комитетының 2019 елның 2 июлендәге 249 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында**

Авыл җирлекләре территорияләренең тотрыклы үсешен тәэмин итүнең социаль, икътисадый, экологик һәм башка факторларын билгеләү, инженер, транспорт һәм социаль инфраструктураны үстерү, гражданнарның һәм аларның берләшмәләренең мәнфәгатьләрен исәпкә алуны тәэмин итү максатларында, Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексы, «Россия Федерациясендә җирле үзидарәнең гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы Уставы нигезендә Балтач район башкарма комитеты карар бирә:

1. «Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы авыл җирлекләренең генераль планнары проектын әзерләү буенча Нигезләмәне раслау һәм комиссия төзү турында» Балтач район башкарма комитетының 2019 елның 2 июлендәге 249 номерлы карарына һәм аның кушымталарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

- исемендә һәм алга таба текст буенча

"генераль планнарның", "генераль планның" сүзтезмәсен "территорияне территориаль планлаштыруның шәһәр төзелеше документлары" сүзтезмәсенә алмаштырырга.

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында бастырып чыгарырга һәм Интернет мәгълүмати-телекоммуникацион челтәрендә Балтач муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Татарстан Республикасы Балтач районы башкарма комитетының төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык бүлеге башлыгына йөкләргә.

Җитәкче А. Ф. Хәйретдинов